# Кодаш авыл жирлеге советынын

# 2013 елга отчет доклады

Хормэтле Андрей Сергеевич!  Хормэтле авылдашлар!

Килгэн кунаклар!

Хэр елны январь,февраль айларында районыбызда,авыл жирлеклэндэ,авыл башлыклары,узлэренен халкы, сайлаучылары алдында башкарылган эшлэренэ отчет ясый, алга таба эшлэргэ бурычлар,йоклэмэлэр билгели. Шулай  ук бу жыелышта авыл халкы район башлыгы,район башкарма комитеты житэкчесе хэм анын ярдэмчелэре, район пенсия фонды, социаль яклау хезмэткэрлэре,БТИ оешмасы,жир хэм милек комитеты житэкчелэре, районнын башка оешма житэкчелэре белэн очрашалар. Алар республика,район яналыклары  белэн таныштыра, башкарылган эшлэр, алда торган бурычлар, халыкны борчыган торле сорауларга жавап бирэлэр.

Кодаш авыл жирлегенен отчет чорында 9 авыл жирлеге Советы утырышы жыелып, анда 15 кон тэртибе каралды. Бу утырышта барлык депутатларыбызда актив катнаштылар,эшлекле хэм авыл тормышына кагылышлы такъдимнэр ясадылар. Утырышларда Кодаш авыл жирлегенен уставына узгэрешлэр керту,бюджетны кабул иту, жирле салымнар жыю, коммуналь тарифлар,учреждение-предприятие эшлэрен оештыру,бэйрам уздыру хам башка мэсэлэлэр каралды. Морэжэгэтлэр ,сораулар,шикаятьлэр аерым кенэгэгэ язмача алып барыла.

Кодаш  авыл жирлеге : Кодаш,Биектау,Иске Кызыл-Яр, Янга Кызыл-Яр, Кыдырлы авылларын берлэштерэ.Гомуми  майданы 5923 гектар. Авылларыбызда барлыгы249 шэхси хужалык исаплэнэ, шуларнын 56 жэйге чорда  кайтып яшилэр хэм 17 буш йортлар. 5 авылда барлыгы 462 кеше исэплэнэ Бу сан бездэ пропискада торып, узлэре читтэ яшэучелэр дэ керэ. 227ир-атлар,235 хатын-кызлар.Яшлэре буенча 1-6 яшькэ кадэр 42бала, 7-17 яшькэ кадэр 36 бала, 18-30 яшькэ 87кеше,31-40 яшькэ кадэр 49кеше, 41-50 яшькэ кадэр 58 кеше,51-60 яшькэ кадэр 80 кеше, 61-69 яшькэ кадэр 41кеше,70 яшьтэн олкэнрэклэр 67 кеше яши. Авылларда яшэуче халыкнын уртача яше 49.5 яшькэ туры килэ.Пенсионерлар148, студентлар 12,Россия армиясе сафларында 2, эш яшендэ торле оешма-учреждениелэрдэ

эшлэучелэр 225 кеше. 2013 нче елда  башкарма комитет тарафыннан 5 балага туу акты , 7 улем теркэлде.

Авылларыбызда   16 тыл ветераны,1 афган,1чечен республикасында хезмэт итеп кайтучы исэплэнэ.

Авыл жирлеге Советы хэм башкарма комитетынын топ бурычы булып,авылларыбызнын халкы турында  кай гырту , аларнын утенечлэрен, телэклэрен , кинэшлэрен тынлап, аларны хэл иту.

Авыл жирлеге Советы, башкарма комитеты, авыл клублары,мэктэп-бакчалар, Ак-барс авыл хужалыгынын 4-филиалы,Боек Жину 9 нчы май, олкэннэр коннэрен зур эзерлек белэн билгелэп уттелэр. Олкэннэр хэм инвалидлар декадасында авыл жирлеге Советы, ветераннар Советы житэкчелеге,оешма житэкчелеге, авылларыбызнын хэрбер олкэн кешесен зурлап кечкенэ генэ булсада булэклэр тапшырдылар, тугэрэк остэл янында кайнар чэй белэн сыйладылар, э клуб,мэктэп-бакча хезмэткэрлэре авылыбыз узешчаннэре коче белэн зур концерт куйдылар.Сонгы елларда ураза бэйрэме ифтар ашы, сабантуй,янга-ел кичэлэре уткэрудэ авыл жирлеге Советы, Ак-барс авыл хужалыгы житэкчелеге,шэхси эшмэкэрлэр зур булышлык курсэтэлэр. Ветераннар Советы рэисе Гараева Гузэл Миннэхмэт кызы белэндэ узара ярдэмлэшеп,анлашып эшлибез.

Авыл жирлеге территориясендэ яшэуче халык узлэренен утенечлэре белэн Совет хэм башкарма комитетка морэжэгать итэлэр. Гражданнардан кергэн утенечлэр куп торле. Морэжэгатьлэрнен купчелеге олкэн яшьтэгелэр тарафыннан: хезмэт стажын эзлэу, тиешле льготалардан файдалану турында. Торле оешмаларга гаилэ хэле, яшэу урыны, агач материаллары, полиция органнарына, хужалыкларында терлек булуга карата, коммуналь мэсьэлэлэр, жир пае, молкэт рэсмилэштеру хэм башка куп торле белешмэлэр,справкалар бирелэ. Кодаш авыл жирлегендэ гражданнарны кабул иту авыл жирлеге башлыгы, башкарма комитеты урынбасары тарафыннан башкарыла. Кабул иту урыны Кодаш авыл жирлеге бинасында, кобул иту очен коннэр хэм сэгатьлэр билгелэнгэн.

Авыл жирлегенен материаль ярдэм курсэту очен чыганагы булмасада, бик авыр хэлдэ калучыларга, морэжэгать итучелэргэ, хормэткэ лаеклы иптэшлэргэ булышлык курсэтудэн читтэ калмый. Бигрэктэ район оешмалары белэн хэл ителэсе уэ остебезгэ алырга, вакытында жавап бирергэ

тырышабыз. Шуны эйтэсе килэ, 2013 елларда 220 шэхси хужалык пай жиренэ , дэулэт регистрациясе палатасы аша уткэрелде.

Хормэтле авылдашлар!

Бугенге кондэ авылда яшэуче шэхси хужалыклардагы терлеклэр саны тубэндэгечэ:

| | 01.01.2013 | 01.01.2014 |
|---|---|---|
| Могезле эре терлек | 181 | 207 |
| Шул исэптэн Сыерлар | 96 | 106 |
| Сарык-кэжэлэр | 46 | 68 |
| Атлар | 2 | 2 |
| Каз,урдэк,тавык | 377 | 363 |
| Куяннар | 9 | 18 |
| Бал кортлары | 148 | 48 |

Авыл жирлегендэ шэхси хужалыклардан сот жыю, сату буенча Зайнетдинов Фаниз, Шаракин Илшат шогеллэнэ. Ел эйлэнэсе 76 тонна сот халыктан жыелган хэм сатылган. Хэр ай саен вакытында, халыктан жыелган сот очен акчалата расчет ясалып барыла. Бугенге кондэ Зайнетдинов 14 сум70 тиен, Шаракин Илшат 14 сум белэн исэплэшэлэр.

2013нче елда ин куп сыер асраучы хужалыклар белэн таныштырам.

1. Закирова Надежда 8 баш
2. Низамбиев Анвар 5 баш
3.Потапова Роза 5 баш
4. Зарифуллин Айрат 4 баш
5.Вахитов Инсаф 3 баш
6. Абзалиев Наил 3 баш
7. Юсупов Рафил 3 баш

10. Исламов Расим 3 баш
11. Шакиров Фанис 3 баш
12. Шаяхметова Раушания 3 баш

8.Смирнов Сергей 4 баш

9.Шайдуллин Рафис 4 баш

Шуны эйтэсе килэ: халыктан жыелган сотнен бэясе тубэн булуы борчый. Куп кенэ хужалыклар сотне узлэре базарда сатуны кулайырак курэлэр. Безнен авыл жирлегендэ сыер асрау отышлы,малны куп асраучы хужалыкларда куп. Алар житештергэн итлэрен, уз хужалыкларыннан артканын сата. 2013 елда 96 баш торле авырлыкта маллар сатылган.

Сонгы елларда авыл халыкнын тормыш шартларын яхшырту максатыннан дэулэт тарафыннан торле льготалы (ЛПХ) кредитлары бирелэ. 2013елда авыл жирлегендэ барлыгы 14 хужалык 2млн. 741 мен сум кредит алган. Сонгы 2012елда кадэр 10 хужалык 1млн.570 мен  сум кредит алган. 2013нче елда хокуматебез сыер токан хужалыкларга  2000 сум кулэмендэ акчалата ярдэм бирелде ( 1 сыерга). Могезле –эре терлеклэргэ фураж, печэн эзерлэргэ, сатып алырга, остэмэ файда булды.

Кодаш авыл жирлегендэ бугенгесе кондэ 65 жинел машина, 8йок машинасы, 23 трактор, 4 комбайн бар. Безнен авыл жирлегендэ шэхси хужалыкларда техникалар, авыл хужалыгы машиналары куп,халык нык торуга карамастан, крестьян-фермер хужалыгы, семья фермалары ачучы гаилэлэр юк. Э менэ пай жирлэрен алып файдаланучылар Биектау авыланнан:

1.Низамбиев Энвэр    9га            54 га арендага алып эшкэртэ

2.Кагиров Резил   4,5 га

3. Ибрагимов Шамил 13,5 га      4,5 га арендага алып эшли

4.Арсланова Фансия       9 га

5.Сабитова Фаридэ       4,5га

7.Муфтиев  Радик          13,5га       4,5 га арендага алып эшли

8.Фаррахова Айгуль     13,5га

Бу гаилэлэр  алынган жир участокларында арпа,бодай хэм купеллык улэн культуралары чэчеп, унышын уз кочлэре белэн жыеп алалар. Узлэреннэн арткан продукцияне сату белэн шогеллэнэлэр, узлэренен семья бюджетына зур табыш китерэлэр. Аларга бу эшлэрендэ тагында зуррак унышлар телисе килэ.

2011,2012 хэм 2013 елларда Татарстан хокумэте тарафыннан семья фермалары оештыру очен торле программалар тэкъдим ителэ. Семья фермалары ачарга телэклэре булган семьяларга, авыл жирлеге, Эгерже районы авыл хужалыгы хэм азык-толек идарэсе белгечлэре булышлык курсэтергэ хэрвакыт эзер. Татарстан хокумэте республикабызнын хэр авыл жирлегендэ берничэ семья фермалары оештыруны бурыч итеп куя.

Хормэтле авылдашлар!

2013 нче бюджет утэлеше буенча тубэндэгелэрне эйтергэ момкин. Доход олеше 2 млн. 237505 сум булырга тиеш булса, э расход олеше 2 млн. 212188 сум тэшкил итэ.

Налоглар жыю буенча тубэндэге цифрларга тукталып китэсе килэ. Физик затлар кереме 209397сум, жир налогы 334234 сум жыелды. Ел дэвамында 22000 сум узара салым, су кулланган очен, 72300 сум жыелган утэлеше 96% клубларнын тулэуле хеэмэте 2000 сум. Шулай ук госпошлина хэм арендадан40257 сум акча керде. Бугенге жыелыштан файдаланып, шуны эйтэсе килэ, налоглар жыйганда хэрбер хужалык узенэ тиешле налогны уз вакытында тулэсен иде.

Ел дэвамында, авыл жирлегендэ урамнарны чуплэрдэн,чуп-улэннэрдэн, зиратларны тэртиптэ тоту, урамнарны яктырту, су магистральлэрен, колонкаларны койлэу, краннар, полиэтелин торбалар,су насослары алу, су очен элетр энергиясенэ тулэу, чуплеклэрне тэртипкэ китеру, кыш коне урамнарны кардан чистарту, налоглар тулэу, торле бэйрэмнэр уткэру, спорт ярышлары уткэру - болар барысыда чыгымнар сорый. Бу эшлэрне башкару очен бюджетта артык акча каралмаган. Шуна курэ узара салым хэм суга жыела торган акча, алда санап кителгэн эшлэргэ тотыла. Авыл жирлегендэ, узара салым хэм суга тулэу акчасын уз вакытында тулэуче хужалыкларкуп, лэкин шул суммаларны тулэмэуче хужалыкларда юк тугел. Бугенге жыелышта аларны эйтеп китмичэ булмый:

| | |
|---|---|
| 1.Баранова Галина | 7.Тимуршина Розалия (2-4кв.) |
| 2. Галирахманова фания | 8.Сабитов Роберт |
| 3.Хуснутдинов рафаэл ( узара салым) | 9.Ибрагимов Ленар |
| 4.Шаяхметова Раушания (2-4кв.уз.с) | 10.Васильева Ираида |

5.Шульмин Сергей

6.Тимургазин Рафинат

2013 елда узарасалым кеше башына 100 сумнан жыелган иде. Быел да 100 сум дисэк, нэрсэ диярсез. Тавышка куям.

Су налогы 10 сумнан жыйган идек, быел 10 сум дисэк риза булырсызмы? Тавышка куям.

Бюджетка су хэм узара салымнан 94300 сум жыелган акчадан, ДРЛ электр лампалары, 4 су насосы ремонтлау очен22300  сум, 2 су насосы  алу очен 44 мен сум, пожарный инвентарь-мото помпа алу очен 28мен сум тотылды..

Хормэтле авылдашлар!

Биектау авылынын Сайдаш урамында берничэ  электр баганалары алышынды.

Авыл жирлеге территориядэге оешмалар хэм башка оешмалар белэн ярдамлэшеп эшли.

Язын-козен зиратларыбызда, юл кырыендагы чуплэрне жыю, чуп улэннэрен чабу, баганалар агарту, яфрак-азык эзерлэу омэлэре оештырылды.

Урамнарда, полисадникларда чэчэклэр устеруче гаилэлэр елдан-ел артып бара, авылларыбыз урамнарына ям остэп тора.

Чуплэрне бер урынга жыештыру, авылларыбыз урамнарын кардан чистарту, янгын сундеру эшлэре эйтеп кителэчэк оешмалар хэм анын житэкчелэре ярдаменнэн башка гына булмый:

1.”Ак-Барс” Эгерже авыл хужалыгы берлэшмэсенен 4нче филиалы житэкчесе Салахиев  Фирдавес Мохамматдин улына.

2.”Ак-Барс” Эгерже авыл хужалыгы берлэшмэсенен 5 нче филиалы (селхозтехника) житэкчесе Кашапов Рашит Габдулхай улына.

3.Селхозхимия директоры Латыйпов Адел Наил улына.

4.”Ритек” мастеры Иванов Александр Сергеевичка.

5. Янгын сундеру оешмасы житэкчесе Мастикаев Рэшит Сэит улына, Фасхетдинов Илнурга ,барыбыз исеменнэн дэ рэхмэт житкерэсе килэ.

Авылларыбызда янгын куркынычсызлыгы топ проблема булып кала, 2011-2012 елларда Кодаш хэм Биектау авылында 4 шэхси йортларнын януы шуны раслый. Авыл жирлеге территориясендэ янгын сундеру машинасы булмау, булган машинанын насосы булмау сэбэпле бик кыен хэлгэ калдыра.

Янгын турында хэбэр иткэннэн сон да , янгын сундеручелэр безгэ 40-60 минут эчендэ килеп житэ алалар, чонки безнен территориягэ Биектау авылы башыннанда, Сарсак-Омга –Иске-КызылЯр авыллары ягыннанда тимер юл чыгасы бар.

Тагын борчыган мэсэлэлэрдэн:  1.Биектау авылында су проблемасы, яна скважина казу, нихэять бу проблема быел респубикабызнын “чиста су” программасына кертелде. 2. Кодаш авылынын Мэскэу,Дуслык, Янга урамнарынын 1967елгы электр баганалары .3.Кодаш авылынын Яшлэр, Дуслык, Янга урам, Биектау авылыннан Колхоз ,Тынычлык урамынын тоньяк олешенен юллары.

Тагын борчыган мэсэлэлэрдэн авыл жирлегенэ бер бульдозерлы трактор булдырылса яхшы булыр иде.(чуплеклэрне жыештыру, кышын авыл урамнарын кардан чистарту хэм башка эшлэр)

Авыл жирлеге территориясендэ  “Ак-Барс” Эгержэ авыл хужалыгы берлэшмэсенен 4 нче филиалы житештеру оешмасы,  Иске-Кызыл-Яр авылында Васильевнын сарыкчылык фермасы ,Янга Кызыл-Яр авылында Мифтахетдинов Флур кортчылыгы, авылларыбыз халкы очен: 2 мэктэп-бакча, 2 авыл клубы, 2 фелдьшер-акушер пунктлары, 1 библиотека, 2 сельпо кибете, 1 шэхси кибет, 1 почта булекчэсе, 2 социаль ярдэм курсэту хезмэткэре, 1 участковый инспектор,3 мэчет матур гына хезмэт итэлэр.

## Авыл хужалыгы

Авыл халкына тормыш итэргэ ботен унайлыклар тудырган, агрофирманын Кодаш хэм Биектау булекчэлэрендэ 96 кеше эшли.Продукция сатудан барлык кергэн керем 39млн.761мен,шунын ит сатудан 4млн.690мен,сот сатудан 25млн.407мен сум.  Хезмэт житештеручэнлеге  1 эшчегэ 224 мен сум.

.Мифтахетдинов Флур 12 цетнер бал сатты.

Агрофирма житэкчелеге ел давамында узенен хезмэткэрлэренэ хезмэт хакларын уз вакытында биреп бара. Бугенгесе кондэ “АкБарс-Эгерже” агрофирмасынын 4 нче филиал игенчелэренен язгы-кыр эшлэренэ

тракторларны, машиналарны хэм тагылма техникаларны ремонтлау, язгы-кыр зшлэрен кыска срокларда,уз вакытында башкарып чыгу бурычы тора. 2013 нче елда Агрофирма халыкка пай жирлэре очен ашлык бирде.

## Мэгэриф системасы

Укыту-тэрбия эшенэ килгэндэ мэктэп-бакчаларыбызда 12бала укый, 22 бала яслегэ йори.  Биектау бакчасына йорергэ телэуче балалар бар,лэкин урын житми. Барлыгы 13 хезмэткэр эшли, 6сы педагогик кадрлар. 4 укытучы да югары белемле ,2 тэрбияче махсус урта белемле. Бу уку елында 3 укытучы атестация узып, уз квалификациялэрен расладылар.

2013-14 уку елынын 1 яртысын укучылар 100% олгереш,71% сыйфат белэн тогэллэделэр. Ел буена торле конкурсларда катнашып килэлэр,хэм булэккэ лаек булдылар.

Бу уку елында  Мэгэриф министрлыгынын зур тикшеруе булып узды, ноябрьдэ район семинары уткэрелде, мэктэп-бакча эшчэнлегенэ унай бэя бирелде.

Проблемаларга килгэндэ, Мэктэп Кодаш авылында республика программасыбуенча капиталь ремонтка кертелде,котельный хэзерге вакытта авария хэлендэ,кичекмэстэн ремонт кирэк. Биектау авылындагы зданиегэ электр линиясен 1 фазадан 3 фазага кучеру буенча документ эшлэре башкарылды. Здание иске булу сэбэпле фундаментлары тузган, бугенгесе кондэ 7тэрэзэ пластикка  алыштырылды ,тубэгэдэ ремонт тэлэп ителэ.

Алга таба 40 урынга исэплэнгэн балалар бакчасы тозу очен республика программасына заявка бирелде.  Укучылар бушлай кайнар аш белэн тэимин ителгэннэр, продукцияне Чаллыдан китерэлэр .

Дэреслеклэр бушлай.,Остэл,урындык,кроватьлар,суыткыч шкаф бирелде. Ел дэвамында мэктэп-бакча коллективы кече хэм башлангыч класс яшендэге балаларны тэрбиялэу, балаларнын физик усешен камиллэштеру, мэктэп-бакча коллективы  ата-аналар белэн тыгыз элемтэдэ торып, анда торган бурычларны хэл итудэ бергэлэп эшлилэр.  5 нче сыйныфтан укучылар Иж-Буби хэм Тирсэ урта мэттэплэренэ автобус белэн йореп укыйлар.

## Медицина

Медицина хезмэтен Кодаш, Биектау  фелдьшер акушер пунктлары, э  Сарсак-Омга фелдьшер акушер пунты Иске-КызылЯр авыл халкына курсэтеп килэ. Кирэк даруларны алып кайтып торалар, процедуралар ясала, ойлэргэ барып

ярдэм курсэтелэ. ФАП ка йореш Кодаш авылында 2518, Биектау авылында1839.2013 елда Кодаш ФАПына 100 мен сумлык ремонт уткэрелде.

## Мэдэният

Культура хезмэтенэ килгэндэ, Кодаш хэм Биектау авыл клублары халыкка тиешле дэрэжэдэге мэдэни хезмэт курсэту, яшьлэр хэм яшьусмерлэр белэн эшлэу, яшь талантларны барлау, халкыбызнын борынгы гореф-гадэт йолаларын кире кайтару, торле кичэлэр хэм традицион бэйрэмнерне кунелле, авылларыбыз халкынын кунеленэ кереп калырдай итеп уткэруне максат итеп эшлилэр. Бугенге кондэ культура тармагы буенча :

1. Кодаш хэм Биектау авыл клубларына 200 урынга исэплэнгэн , 500 мен сумлык ,яна урындыклар алынды. Бу эшне башкарып чыгуда зур ярдэм курсэткэн Татарстан Республикасы мэдэният министры ярдэмчесе Ираида Хафизъяновнага зур рэхмэтемне житкерэсе килэ. Биектау авыл клубы да тубэ алыштыру, тышкы як косметик ремонт эшлэренэ мохтаж.

Кодаш авыл китапханэсендэ 8640 данэ китап исэплэнэ. Ел дэвамында китапханэдэ торле темаларга карата китап кургэзмэлэре оештырыла. Кече яшьтэге мэктэп укучылары белэн эдэби уеннар уткэрелде.

Хезмэткэрлэр саны - 3.

## Сэудэ

Сэудэ хезмэте буенча жирлектэ бугенге кондэ 2 РАЙПО хэм 1 шэхси кибет эшли. Кибетлэргэ кирэк товарлар хэрвакыт кайтып тора. Кодаш авылындагы РАЙПО кибетенен товар эйлэнеше белэн таныштырып утэм. 2012 елда 3млн 603мен 200сум булган.2013 елда 3млн.739мен. 200сум. Утэлеш 103,8%.

## Почта-элемтэ

Биектау почта булеге 4 авылга хезмэт курсэтэ, 2 кеше эшли . Почта булекчэсенэ йомышы тошмэгэн кеше юктыр, могэен. Кон буе аннан халык озелми. Элемтэ булеге 126 кешегэ пенсия, 142 кешегэ субсидия хэм пособиелэр бирелэ. Утка- газга, телефонга тулэу, спутник антенналарына тулэу, сотовый телефоннарга тулэу эшлэре башкарыла. Шулай ук ГИБДД штрафлары, балалар бакчасы очен тулэу момкинлеге тудырылды. Элемтэ булеге ай саен 22мен сумлык товар сату планын ути. Кодаш хэм Биектау авылларына 90 торле газет-журналлар авыл халкына узвакытында олэшенэ.Ин куп яздырылган гэжитлэрдэн; Эгержэ хэбэрлэре, Агрызские

вести белэн 94 хэм Ватаным Татарстан.

Социаль ярдэм.

Материал ярдэм 1кешегэ 5000 сум кулэмендэ бирелде. Авылларыбызда караучысыз калган10 олкэн кешелэргэ 2 социаль хезмэткэр хезмэт курсэтэ. Красный Бор тернэклэндеру узэгендэ 16 кеше ял итеп, сэлэматлеклэрен ныгытып кайттылар.

Дини йолаларны утэу эшлэрен, зиратларыбызны, мэчетлэребезне тэртиптэ тотуда, имамнарыбыз Кодашта-Миннефлур ага, Биектауда-Низамбиев Энвэр, Иске –КызылЯрда Зиганшина Жэухэрия апалар зур эш башкаралар.

Авылларыбыз иминлеге темасына килгэндэ, монда эшлисе эшлэр бар эле, кайбер гайлэлэр белэн, эти-энилэр,мэктэп-бакча коллективы балалар белэн, барыбызгада кагыла, ныклап тэрбия эшлэре алып барырга тиешбез.

Хормэтле гражданнар!

Авыл жирлегенен эше куп кырлы. Халыкка кагылышлы барлык мэсьэлэлэрдэ авыл жирлегенэ кайтып кала. Булган проблемаларны авыл жирлеге бинасында утырган иптэшлэр белэн генэ хэл итеп булмый, без барыбыз да бердэм булып, кайда гына эшлэсэк тэ, тормышка битараф булмыйча, узебезнен яшэгэн авылларнын килэчэген яхшыртып, матурлыкка омтылып, узебезнен сафларны арттытып, еллар имин булсын, куйган максатларыбызга ирешергэ Ходай насыйп итсен, бергэлэп эшлэргэ хэм яшэргэ язсын.

Шунын белэн отчет доклады тэмам. Кайбер эйтелмэгэн эшлэр, эйтелэсе сузлэр булса узегеэнен чыгышларыгызда тулыландырырсыз, уз тэкъдимнэрегезне эйтерсез дип ышанып калам.

Игътибарыгыз очен зур рэхмэт!

ПЛАН МЕРОПРИЯТИЙ ПО ВЫПОЛНЕНИЮ ПРЕДЛОЖЕНИИ ВЫСКАЗАННЫХ НА СОБРАНИИ ГРАЖДАН КУДАШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РТ
ОТ 12 ФЕВРАЛЯ 2014 года

1. Замена электрических опор от КТП-400 до ул. Новая, ул. Новая, Московская, Дружба, Тукая .
2. Внутри уличные дороги с. Кудашево - ул. Молодежная, Дружба,Новая., с.Биктова- ул. Колхозная.
3. Нуждается трактор-бульдозер для благоустройство сел, пожарная машина.
4. Отрыть почтовое отделение с. Кудашево (помещение имеется, газовое отопление)